| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2023 г. Казань № 640-106/кс-2023

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 27.11.2019 №10-126/кс карарына үзгәрешләр кертү һәм белән Зеленодольск муниципаль районының «ЗВКС» акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 27.11.2019 №10-126/кс карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2024 ел өчен төзәтмә кертү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 14.12.2023 №58-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә, билгеләнгән тарифлар кагыла торган кулланучыларны тәгаенләштерү һәм эчә торган суга, су агызуга 2024 елга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай кеременә төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Зеленодольск муниципаль районының «ЗВКС» акционерлык җәмгыяте өчен 2020-2024 елларга эчә торган суга һәм ташландык су агызуга тарифлар билгеләү турында» 27.11.2019 №10-126/кс карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 02.12.2020 №328-138/кс-2020, 18.11.2022 №598-172/кс-2022 карарлары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «ЗВКС» акционерлык җәмгыяте өчен, әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә, календарь буенча бүлеп, эчә торган суга һәм су агызуга тарифлар билгеләргә.»;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «ЗВКС» АҖ иректә файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С. Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
27.11.2019 №10-126/кс
карарына (Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
14.12.2023 № 640-106/кс-2023
карары редакциясендә) 1 нче кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «ЗВКС» акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2020-2024 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Ташландык су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | Зеленодольск муниципаль районы | | | |
| 1 | «ЗВКС» акционерлык җәмгыяте (Зеленодольск шәһәре, Васильево ш.т.п., Әйшә, Свияжск (Зөя) авыл җирлекләре кулланучылары өчен) | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелә)* | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 20,40 | 19,30 |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 21,24 | 20,06 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 21,24 | 20,06 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 21,90 | 20,92 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 21,90 | 20,92 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 23,22 | 22,16 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 25,60** | 24,82** |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 25,60 | 24,82 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 30,77 | 29,15 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 17,00 | 16,08 |

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Ташландык су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 17,70 | 16,72 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 17,70 | 16,72 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 18,25 | 17,43 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 18,25 | 17,43 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 19,35 | 18,47 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 21,33** | 20,68** |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 21,33 | 20,68 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 25,64 | 24,29 |

* Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла.
** 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.11.2022 №598-172/кс-2022 карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге